Татарстан Республикасы Кукмара муниципаль районы
Түбән Үрәс авыл җирлеге башлыгы

# КАРАРЫ

12 ноябрь 2020 ел №4

Гражданнарның үзара салым акчаларын кертү
һәм куллану мәсьәләсе буенча Кукмара муниципаль
районы Түбән Үрәс авыл җирлегенең Иске Уча авылында
гражданнар җыенын билгеләү турында

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 25.1, 56 статьялары, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы, Кукмара муниципаль районы Түбән Үрәс авыл җирлеге Уставының 22 статьясы нигезендә карар бирәм:

1. 2020 елның 25 ноябрендә сәгат 10.00 Кукмара муниципаль районының Түбән Үрәс авыл җирлегенең Иске Уча авылында үзара салым кертү мәсьәләсе буенча гражданнар җыенының беренче этабын билгеләп үтәргә. Халык җыенын авыл клубы бинасында түбәндәге адрес буенча уздырырга: Иске Уча авылы, Первомайская урамы, 21 йорт.
2. 2020 елның 25 ноябрендә сәгат 15.00 Кукмара муниципаль районының Түбән Үрәс авыл җирлегенең Иске Уча авылында үзара салым кертү мәсьәләсе буенча гражданнар җыенының икенче этабын билгеләп үтәргә. Халык җыенын авыл клубы бинасында түбәндәге адрес буенча уздырырга: Иске Уча авылы, Первомайская урамы, 21 йорт.
3. Гражданнар җыенына чыгарыла торган сорауны түбәндәгечә расларга: “Сез яшәү урыны буенча Кукмара муниципаль районының Түбән Үрәс авыл җирлегенең Иске Уча авылы территориясендә теркәлгән көндезге уку бүлегендә укучы студентлар, 1 төркем инвалидлар һәм 80 яшьлек һәм аннан өлкәнрәк затлардан кала һәр балигъ булган яшәүчедән 2021 елда 500 сум күләмендә үзара салым кертү һәм аны:

- янгын сүндерү машинасын карап тоту ( ягулык-майлау материаллары, запас частьләр сатып алу);
- урамнарны яктырту буенча энергия саклаучы лампалар сатып алу;
- авыл җирлеге торак пунктларында урам юл челтәрен карап тоту;
- Иске Уча авылы Набережная һәм Восточная урамнарындагы юлларга вак таш җәю; проект - смета документациясе һәм техник күзәтчелек өчен шартлар булдыру кебек эшләр башкаруга юнәлтү белән ризамы?»

«РИЗА» «КАРШЫ».

4. Гражданнар җыенын үткәрү өчен торак пунктта яшәүчеләр исемлеген территориаль билгеләр (урамнар буенча) буенча бүлергә.

5. Түбән Үрәс авыл жирлегенең башкарма комитеты гражданнар жыенын оештыручы итеп билгеләргә.
6. Әлеге карарны мәгълүмати стендларда һәм Кукмара муниципаль районының рәсми сайтында жирлекнең «Авыл жирлекләре» бүлегендә кабул ителгән көннән алып 5 көн эчендә игълан итәргә.
7. Әлеге карар басылып чыккан көненнән үз көченә керә.

Түбән Үрәс Авыл
жирлеге башлыгы: Р.Х.Шамеев